| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Исполнительный комитет**<br>**Александровского сельского**<br>**поселения Сармановского**<br>**муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль**<br>**районының**<br>**Александровка авыл**<br>**җирлеге башкарма**<br>**комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с.Александровка **КАРАР**

31 январь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 7793,48 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитетының» "Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында "2022 ел, 28 январь, 1 нче номерлы карарын үз көчен югалткан санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Александровка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф.Вафин

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2023 елның 31 январендәге 1 нче карарына
1 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4840,47 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1504,36 |
| Барлыгы | **7793,48** |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2023 елның 31 январендәге 1 нче карарына
2 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Кәфенләү | 1568,46 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3266,44 |
| 4.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1509,93 |
| Барлыгы | **7793,48** |